ТАТАРСТАН Республикасы
Аксубай муниципаль районы
муниципаль беремлеге
Емелькино авылы

Республика ТАТАРСТАН
Аксубаевский
муниципальный район
муниципальное образование
село Емелькино

**Совет Емелькинского сельского поселения**

423056, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Емелькино, ул. Центральная д.16
Тел.(8-84344-4-76-22) ОГРН 1021605364980, ОКПО 94318599,ИНН/КПП 1603000796/160301001

## КАРАР

№ 26 2021 елның 27 мае

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»
2019 елның 27 ноябрендәге 103 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

РФ Салым кодексының 397 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай районы прокуратурасының 2021 елның 1 февралендәге 02-08-02 номерлы протестын үтәү йөзеннән һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 27 ноябрендәге 103 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне кертергә:

1.1«Салым һәм салым буенча аванс түләүләрен түләү тәртибе» 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлекләре урнашкан урын буенча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1/4 процент өлешенең тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.»

2. Үз көчен югалткан дип танырга:
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 15 ноябрендәге 114 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 25 мартындагы 21 номерлы карары;
3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: http:// Aksubayevo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге башлыгы.
Совет Рәисе Н.И.Михайлова